**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**муниципального образования**
**«город Тетюши»**
**Тетюшского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Тәтеш муниципаль районы**
**«Тәтеш шәһәре»**
**муниципаль берәмлеге**
**СОВЕТЫ**

тел. (84373) 2-50-02, факс 2-51-58, e-mail: motetushi@rambler.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 32-6** **12.12.2024**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 10 декабрендәге 21-3 номерлы карары белән расланган «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе, «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 маддәсе нигезендә «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 10 декабрендәге 21-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«16) Россия Федерациясе халыкларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә карамастан Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр);".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге
Башлыгы урынбасары **А.И. Чермянин**